**Өмет**

Кичке урам - тулы сихри тынлык:
Салмак кына ява йомшак кар,
Аяк асты шыгыр-шыгыр килә,
Һәр тарафта серле тылсым бар.

Кышка зур өметләр баглый кеше,
Яңа елдан көтеп могҗиза.
Алтын-көмеше дә кирәк түгел,
Тыныч булсын тик безнең дөнья.

Җиһанны гүя ак келәм каплый
Яшергәндәй галәм михнәтен.
Салса иде сафлык күңелләргә,
Алсын җаннан заман зәхмәтен.

*Резедә Шәмсуллина*